ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 октябрь 2025ел

№ 8536

«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданнар оборонасы» 03.09, «Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү» 03.10, «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01, «Гомуми белем бирү» 07.02 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә: 2026 елда – 35820,56 мең сум, 2027 елда – 37898,48 мең сум, 2028 елда – 37898,48 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://nabchelny.ru адресы буенча урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 21 октябрендәге
8536 номерлы карарына
кушымта

«2026-2028 елларга
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасы паспорты

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td colspan="5">«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасы (алга таба – Программа)</td></tr>
<tr><td>Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, датасы һәм номеры)</td><td colspan="5">«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе</td></tr>
<tr><td>Программаны үтәүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның районнар хәкимиятләре</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты:</td><td colspan="5">Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннарны кисәтү буенча нәтиҗәле система булдыру</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">1. Яр Чаллы шәһәре территориясен һәм халыкны саклау буенча янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;<br>2. Шәһәрнең белем бирү оешмаларында һәм яшьләр сәясәте өлкәсе оешмаларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">1 этап – 2026 ел, 2 этап – 2027 ел, 3 этап – 2028 ел</td></tr>
<tr><td rowspan="4">Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2026 (мең сум)</td><td>2027 (мең сум)</td><td>2028 (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>35 820,56</td><td>37 898,48</td><td>37 898,48</td><td>111 617,52</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 35 820,56 | 37 898,48 | 37 898,48 | 111 617,52 |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | - янгыннар санын һәм янгыннарда травма алган кешеләр санын киметү;<br>- шәһәрнең белем бирү оешмаларында янгын куркынычсызлыгын арттыру | | | | |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Программа чараларын башкаручы аларны сыйфатлы һәм үз вакытында үтәү, бүлеп бирелә торган финанс средстволарыннан рациональ файдалану өчен җаваплы | | | | |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге инфраструктурасының заманча үсеше икътисадый потенциалны ныгытуга, социаль иминлекне яхшыртуга һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшәүче халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән.

Икътисадый куркынычсызлыкны тәэмин итүнең мөһим һәм актуаль критерийларының берсе булып янгын куркынычсызлыгы чаралары системасын оештыру тора. Тәкъдим ителгән муниципаль программаны эшләүнең максатчанлыгы «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгыннан ирекле саклау» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яр Чаллы шәһәре чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү буенча Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкару зарурлыгына бәйле.

Яр Чаллы шәһәре территориясендә барлыкка килә торган янгыннар ел саен шәһәр икътисады һәм халкы өчен зур матди һәм мораль югалтуларга китерә. Нәтиҗәләрнең авырлыгы, кешеләрнең үлем һәм травма алу дәрәҗәсе югары булып кала бирә.

Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр бүлегенең 2020-2024 еллардагы Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннар һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүматлары

| № т/б | Ел | Янгыннар саны | Зыян күргән халык саны, кеше | |
|---|---|---|---|---|
| | | | һәлак булган | травма алган |
| 1. | 2020 | 377 | 8 | 22 |
| 2. | 2021 | 569 | 12 | 27 |
| 3. | 2022 | 469 | 7 | 30 |
| 4. | 2023 | 441 | 5 | 45 |
| 5. | 2024 | 426 | 7 | 34 |

Күпчелек очракта янгын аерым гражданнарның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә җавапсыз мөнәсәбәте, әлеге һәлакәтнең куркыныч булуын һәм аның нәтиҗәләрен алдан күрә белмәве аркасында килеп чыга. Бүген һәр икенче янгын диярлек ут белән саксыз эш итү аркасында, һәр дүртенче янгын электр җиһазларын һәм көнкүреш приборларын урнаштыру һәм файдалану кагыйдәләрен үтәмәү аркасында килеп чыга. Гомумән алганда, янгын куркынычсызлыгы нигезләрен белмәгән гражданнар гаебе белән 90% тан артык янгын килеп чыга.

Янгын чыгу сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Иң гомуми сәбәпләр булып түбәндәгеләр тора:

1) ут белән саксыз эш итү;

2) электр җиһазыннан файдалану кагыйдәләрен бозу, аны төзек булмаган хәлдә файдалану, электр җиһазларын монтажлау кагыйдәләрен бозу, көнкүреш электр приборларын эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу;

3) техник чараларның механизмнары һәм узеллары төзек булмау;

4) мичләрне урнаштырганда һәм эксплуатацияләгәндә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу;

5) яна торган матдәләрне һәм материаллаһәм профилактик эшләр рны саклау урыннарында эретеп ябыштыру эшләрен үткәрү кагыйдәләрен бозу;

6) парлар, газлар, сыеклыклар ташлауны китереп чыгаручы җиһазларның технологик эш режимнарын бозу;

7) материалларны һәм матдәләрне янгын куркынычы булган үзлекләрен исәпкә алмыйча куллану;

8) ут төртүләр.

Әлеге мәгълүматлар, күбесенчә янгын куркынычсызлыгы проблемасын хәл итү, янгынга каршы белемнәр дәрәҗәсенең артуына (янгыннарны профилактикалауга) бәйле булуны раслый.

Белем бирү оешмалары өчен куркынычсызлыкның төрле төрләре арасында янгын куркынычсызлыгы өстенлекле булып тора, аңа икътисадый, профилактик, мәгълүмати һәм оештыру характерындагы чаралар системасы белән, куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәреп ирешелә.

Янгын куркынычсызлыгы, тормыш өчен иң мөһим ихтыяҗ буларак, белем бирү оешмасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критериена һәм мәҗбүри шартына әверелә. Белем бирү оешмасында куркынычсызлык белем бирү процессында барлыкка килү ихтималы булган тискәре вакыйгаларга алдан ук юл куймаслык яки аларны киметерлек итеп оештырылырга тиеш.

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын төзү проблемасы белем бирү оешмаларының үзенчәлекләрен һәм норматив таләпләр нигезендә объектның куркынычсыз торышын саклау, мөмкин булган янауларны ачыклау, аларны булдырмау һәм бетерү юлы белән теге яки башка янаулар барлыкка килү ихтималын исәпкә алып хәл ителергә тиеш.

Белем бирү оешмасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүче төп характерлы факторлары булып түбәндәгеләр тора:

- беренчел янгын сүндерү чаралары белән комплектлаштырылган булу;

- автоматик янгын сигнализациясе, хәбәр итү һәм эвакуация белән идарә итү системасы булу;

- электр җиһазларыннан файдалану кагыйдәләрен үтәү һәм эчке электр челтәрләренең торышы;

- запас эвакуация чыгу юлларын тиешле хәлдә тоту;

- янгын куркынычсызлыгын оештыру буенча норматив-хокукый актлар белән тәэмин итү һәм янгын куркынычсызлыгы чараларын, бигрәк тә гадәттән тыш хәлләрдә үтәү буенча җитәкчеләр һәм хезмәткәрләр әзерләү.

Яр Чаллы шәһәре территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми

һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы 214 муниципаль белем бирү оешмасы урнашкан, шул исәптән:

- гомуми белем бирү учреждениеләре – 83;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре – 131.

Программа муниципаль белем бирү оешмаларының янгын куркынычсызлыгын арттыру буенча норматив-хокукый базасын камилләштерү һәм алга таба үстерү, шулай ук муниципаль белем бирү оешмаларының янгын куркынычсызлыгын арттыру буенча чаралар комплексларын эшләү һәм тормышка ашыру өчен нигез булып тора.

Программа ысулы белән янгыннарны һәм кешеләр үлемен профилактикалау, кисәтү буенча бурычларны хәл итү Яр Чаллы шәһәре халкының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын тормышка ашыруның иң нәтиҗәле инструменты булып тора.

## 3 бүлек. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты булып Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннарны кисәтү буенча нәтиҗәле система булдыру тора.

Программаның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәре территориясендә халыкны саклау буенча янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

2) шәһәрнең белем бирү оешмаларында һәм яшьләр сәясәте өлкәсе оешмаларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Программаны тормышка ашыруның максатчан күрсәткече булып 2024 ел дәрәҗәсенә карата Яр Чаллы шәһәрендә янгын куркынычсызлыгы торышы тора.

Программаның мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнарның сакланышын арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү һәм җиңеләйтү буенча бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсен саклау;

2) муниципаль гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлек дәрәҗәсен саклау.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә социаль һәм икътисадый яктан яраклы янгын куркынычсызлыгы дәрәҗәсенә ирешү, социаль әһәмияткә ия объектларның һәм кешеләр күпләп җыела торган объектларның янгынга каршы сакланышын ныгыту күздә тотыла.

## 4 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыруның арадаш һәм ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү өчен нәтиҗәлелекне бәяләүнең түбәндәге индикаторлары файдаланыла:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү | Мәгълүмат чыганагы |
|---|---|---|---|
| 1. | Автоматик янгын сигнализациясенең авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | $100 - \left(\frac{N}{M} * 100\right)$<br>N – һәлакәтләр саны<br>M – объектлар саны | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | 1. N=100%-(B/A*100%)<br>A- хезмәткәрләр саны<br>B- киемнәр белән тәэмин ителгән хезмәткәрләр саны<br>2. M=100%-(B/A*100%)<br>A- хезмәткәрләр саны<br>B - уку үткән хезмәткәрләр саны<br>(шул исәптән, кабат квалификация алу, квалификация күтәрү)<br>3. E =100%-N-M | «Янгын-коткару отряды» МБУ |

5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2026-2028 елларга программаны финанслау күләме 111 617,52 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2026 елда – 35 820,56 мең сум, 2027 елда – 37 898,48 мең сум, 2028 елда – 37 898,48 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

6 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары.
Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту системасы

Программа 2026-2028 еллар дәвамында гамәлдә.

Программа үтәлешен гомуми контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе гамәлгә ашыра.

7 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Билгеләнгән программа чараларын тормышка ашыру янгын куркынычсызлыгының нәтиҗәле системасын булдырырга, зур янгыннар барлыкка килү ихтималын киметергә, янгыннарда һәлак булганнар һәм җәрәхәтләнгән кешеләр санын киметергә, янгыннардан ел саен матди югалтуларны киметергә, матди-техник базаны ныгытырга һәм «Янгын-коткару отряды» муниципаль бюджет учреждениесенең хәрби әзерлеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программа комплекслы характерда, һәм куелган максатларга ирешү бары тик бер-берсенә бәйләнгән һәм барлык программа чараларын башкарганда координацияләнгән очракта гына мөмкин.

## 8 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| № т/п | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгыннарны кисәтү буенча нәтиҗәле система булдыру | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Яр Чаллы шәһәре халкын һәм территориясен саклау буенча янгынга каршы чараларны тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| 1. | «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ материаль-техник тәэмин итү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2026-2028 еллар | алдан билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 21 619,94 | 23 697,86 | 23 697,86 |
| 2. | Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үтәү | Башкарма комитетның иҗегариф идарәсе | 2026-2028 еллар | алдан билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 33,60 | 33,60 | 33,60 |
| Бурыч: Шәһәрнең белем бирү оешмаларында һәм яшьләр сәясәте өлкәсе оешмаларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| 3. | Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Башкарма комитетның иҗегариф идарәсе | 2026-2028 еллар | автоматик янгын сигнализациясенең авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 4 756,00 | 4 756,00 | 4 756,00 |
| 4. | Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Башкарма комитетның иҗегариф идарәсе | 2026-2028 еллар | автоматик янгын сигнализациясенең авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 7 092,00 | 7 092,00 | 7 092,00 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2028 еллар | автоматик янгын сигнализациясенең авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 707,95 | 707,95 | 707,95 |
| 6. | Яшьләр сәясәте өлкәсе учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2026-2028 еллар | автоматик янгын сигнализациясенең авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 290,70 | 290,70 | 290,70 |
| 7. | Мәдәният учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2026-2028 еллар | автоматик янгын сигнализациясенең авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 445,05 | 445,05 | 445,05 |
| 8. | Физик культура һәм спорт учреждениеләрендә автоматик янгын сигнализациясенең һәм «Стрелец-мониторинг» программа-аппарат комплексы комплекслы адреслы мониторинг системасының техник әзерлеген тәэмин итү | Башкарама комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2026-2028 еллар | автоматик янгын сигнализациясенең авариясез эксплуатация дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 875,32 | 875,32 | 875,32 |
| 9. | «Гомуми белем бирү оешмаларында укучылар арасында «Куркынычсызлык мәктәбе» республика слёт-ярышында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2028 еллар | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | Укучылар арасында янгынга каршы тематикага иң яхшы инша, иң яхшы рәсем һәм гамәли иҗат өлкәсендә иң яхшы эш конкурсында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2028 еллар | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 11. | Шәһәрнең идарәче компанияләре каршында эшләмәүче халыкны укытуны үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2026-2028 еллар | җәлеп ителгән эшләмәүче халык, кеше саны | 10000 | 11000 | 12000 | 13000 | финанслау таләп ителми | | |
| 12. | Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү предметына территориаль иҗтимагый үзидарәләр белән киңәшмәләр оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2026-2028 еллар | чаралар саны, берәмлек. | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 13. | Социаль адаптацияләнмәгән гражданнарның, аерым алганда, спиртлы эчемлекләрне яки наркотик чараларны чиктән тыш күп кулланучы затларның, имин булмаган күпбалалы гаиләләрнең, өлкән яшьтәге гражданнарның, авыр тормыш хәлендә калган затларның яшәү урыннарын тикшерү предметына торак секторны карап чыгу | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | март-декабрь ел саен | катнашучылар, кеше саны. | 3000 | 3100 | 3200 | 3300 | финанслау таләп ителми | | |
| | Барлыгы: | | | | | | | | 35 820,56 | 37 898,48 | 37 898,48 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева